ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ИЖЕВКА ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАРНЫҢ ҮЗАРА САЛЫМ АКЧАЛАРЫН КЕРТҮ ТУРЫНДА

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

20.02.2025 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 22 ноябрендәге 3 номерлы, “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 22 ноябрендәге 4 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәьәләсе буенча 2025 елның 10 февралендәге 1 номерлы карарына нигезләнеп Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 22 ноябрендәге 3 номерлы, “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 22 ноябрендәге 4 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу һәм тигезләү, Мэктэп тыкрыгы, Курорт урамы, Кыр урамы буенча чишмәгә таба, килешү буенча түләү.

2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуның энергияне саклый торган яктырткычларын сатып алу һәм алмаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, генератор сатып алу).

3 торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, ягулык-майлау материаллары һәм килешү буенча хезмәт өчен түләү, карны чистарту, сәхнә түбәсенә каркас-тент сатып алу һәм урнаштыру).

4) су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( суга батыру насослары сатып алу , Юбилей ур., 2 йорт буенча канализация торбасын алыштыру, суыртып алу өчен фикаль насос сатып алу)"

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кара кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Ижевка авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге башлыгы ________ Р.Т.Мәсәгутова

(имза) (имзаның аңлатмасы)